ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 март 2020 ел № 1461

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибе турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгыннар чыгуга юл куймау максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2020 елның 25 мартындагы
1461 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү
тәртибе

1. Янгын куркынычы арткан очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Башкарма комитет карары белән янгынга каршы махсус режим билгеләнә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә түбәндәге өстәмә янгын куркынычсызлыгы таләпләре билгеләнә:

1) әлеге территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы торышын һәм таләпләренең үтәлешен даими контрольдә тоту;

2) аерым участокларда учак ягуларны, янгын чыгу куркынычы булган эшләр башкаруны вакытлыча туктатып тору.

3. Балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыручы (шул исәптән балалар көндез була торган) оешмалар җитәкчеләренә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) ел саен, җәйге ял лагеры эшли башлаганчы, балалар ялын үткәрү чорына янгыннар чыгуга юл куймау буенча чаралар планын эшләргә һәм аны ТР буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы баш идарәсенең Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре бүлеге белән килештерергә;

2) һәр смена башланыр алдыннан хезмәткәрләр белән янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгын була калса эш итүләр буенча инструктажлар үткәрергә;

3) янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгын була калса эш итүләр буенча инструктажларны ял лагерына килүче һәр бала белән үткәрергә;

4) сменага кимендә бер тапкыр, янгын була калса эвакуацияләү планнарын үтәү буенча практик тренировкалар үткәрергә.

4. Яр Чаллы шәһәре территориясендә коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре рәисләренә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендәге җир участокларын һәм алар янәшәсендәге территорияләрне яна торган калдыклардан, чүпләрдән, тарадан һәм корыган үсемлекләрдән чистартуны тәэмин итәргә;

2) коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре әгъзалары арасында бакчачылык җәмгыяте территориясен көн саен карап чыгу мәсьәләсе буенча эшне оештырырга;

3) янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда чүпләрне, яна торган калдыкларны, тара һәм корыган үсемлекләрне яндыруга юл куймаска.

5. Янгынга каршы махсус режим билгеләнгәндә, гражданнарның «Яр буе» паркы урман-парк зонасына керүләрен, шулай ук анда транспорт чаралары керүне чикләү гамәлдә була.

6. Янгынга каршы махсус режим билгеләнгән һәм гамәлдә булган чорда балалар күпләп ял иткән урыннарда, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә оештыру чаралары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча оператив штаб төзелә, ул:

1) Яр Чаллы шәһәрендә, балалар күпләп ял итә торган урыннарда, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә ут сүндерү чаралары һәм беренчел янгын сүндерү чаралары запасларын булдыруны оештыру мәсьәләсен хәл итә;

2) янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү мәсьәләләре буенча максатчан мәгълүмат-пропаганда эшен оештыра;

3) янгыннарны сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зонасыннан эвакуацияләү буенча эш итүләргә өйрәтү буенча дәресләр үткәрә;

4) гражданнар күпләп ял итә торган урыннарны, шулай ук коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрен ирекле янгын формированиеләре әгъзалары тарафыннан беренчел янгын сүндерү чаралары белән патрульлек итүне оештыра.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова